РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«7» март 2025г. г. Альметьевск № 343

«Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Нигезләмә хакында»Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 253 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм хокукый мониторинг тәртибендә

Әлмәт муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Нигезләмә хакында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 253 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 12 мартындагы 367 номерлы, 2020 елның 30 октябрендәге 12 номерлы, 2021 елның 11 мартындагы 36 номерлы, 2021 елның 16 декабрендәге 114 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 143 номерлы, 2023 елның 06 декабрендәге 266 номерлы, 2024 елның 13 ноябрендәге 322 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып ).түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында Нигезләмә хакында» карарның 1 нче кушымтасында:

- 2 бүлек «Комиссия төзү тәртибе» 2.2 нче пунктының «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы башлыгы урынбасары (комиссия рәисе), муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте бүлекчәсе җитәкчесе йә җирле үзидарә органының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы кадрлар хезмәте вазыйфаи заты (комиссия секретаре), кадрлар хезмәтеннән, юридик (хокукый) бүлекчәдән, җирле үзидарә органының башка бүлекчәләреннән муниципаль хезмәткәрләр, аның җитәкчесе тарафыннан билгеләнә торган;»;

1.2. «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе составы» 2 нче кушымтасында:

- комиссия составыннан И.К. Котбиевны чыгарырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Туманова Г.П.).

Муниципаль район Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Е. Афлятунова